РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ГОРОДА АЗНАКАЕВО АЗНАКАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул.Ленина, д.14, г. Азнакаево, 423330

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЗНАКАЙ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Ленин ур., 14 йорт, Азнакай шәһәре, 423330

Тел./факс(885592)7-15-50,7-00-37; E-mail:aznakay@tatar.ru, adm-aznakay@mail.ru; http://aznakayevo.tatarstan.ru/

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

24.08.2023 ел № 123

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә хайваннарны хуҗалардан башка кайтару тыела торган урыннарның исемлеге хакында

«Терлекләр белән җаваплы эш итү турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 498-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 6.1 өлеше, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә хуҗалардан башка хайваннарны кайтару тыела торган урыннарның исемлеген 1 нче кушымта нигезендә билгеләргә.

2. Хайваннарны хуҗаларыннан башка элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карар кабул итүгә җаваплы затлар итеп түбәндәгеләрне билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының шәһәр хуҗалыгы бүлеге башлыгы;
- «Азнакай шәһәрен төзекләндерү һәм яшелләндерү» күптармаклы житештерү предприятиесе» муниципаль унитар предприятиесе директоры (килешү буенча);

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Э.А. Габдрахманов

**Азнакай шәһәре Башкарма**
**комитетының карарына 1 нче кушымта**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
«Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә
хайваннарны хуҗалардан башка кайтару тыела торган урыннар исемлеге

1. Балалар уен һәм спорт мәйданчыклары, спортның актив төрләре белән шөгыльләнү өчен спорт мәйданчыклары, ачык һавада спорт уеннары өчен билгеләнгән мәйданчыклар.

2. Иҗтимагый территорияләр (парклар, скверлар, аллеялар, массакүләм ял итү урыннары, гомуми файдаланудагы су объектларының яр полосалары, елгалар яр буйлары).

3. Мәгариф оешмалары һәм сәламәтлек саклау оешмалары, күрсәтелгән оешмаларга якын территорияләр.

4. Мәдәният һәм сәнгать объектларына якын территорияләр.

5. Җәмәгать туклануы оешмаларына, сәүдә объектларына якын территорияләр, стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру урыннары.

6. Йорт хайваннарын йөртү өчен билгеләнгән урыннар.

7. Күп фатирлы йортларга якын территорияләр, аларда мондый йортларга хезмәт күрсәтү һәм эксплуатацияләү өчен билгеләнгән объектлар һәм бу территорияләрне төзекләндерү элементлары, шул исәптән парковкалар (парковка урыннары), тротуарлар һәм автомобиль юллары, шулай ук күп фатирлы йортларга якын территорияләргә юллар барлыкка китерүче автомобиль юллары.

8. Зиратлар һәм мемориаль зоналар.